| | |
|---|---|
| **ГЛАВА КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘҮҖИЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 ел 2 ноябрь Кәүҗияк авылы № 4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авылы җирлегендә Кәүҗияк авылы гражданнарның 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Уставының 18 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Кәүҗияк авылы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 13ноябрենә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Кәүҗияк авылы җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Кәүҗияк авылына урам яктырткычлары сатып алу;
- газ 3512 махсуслаштырылган техникасын тоту(йөк үзбушаткычы): дизель ягулык- майлау, запас частьләр сатып алу;
- Кәүҗияк авылы территориясендә үлән чабу;
- Кәүҗияк авылының Совет урамындагы зират коймасын тоту өчен төзелеш материаллары сатып алу;
- Кәүҗияк авылының Совет урамындагы зират территориясендә зур агачлар кисү;
- район газетасы «Сарман»да некрологларны бастырып чыгару.

ӘЙЕ ЮК?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгән көннән алып 7 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ә.Хөснетдинов